**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сәпәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сәпәй авылы №156 «21» июль 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 2023 елның 23.10. 100 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (12.04.2024 № 116, 07.10.2024 № 131 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2025 елның 24 июнендәге №158-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Сәпәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 2023 елның 23.10. 100 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә (12.04.2024 № 116, 07.10.2024 № 131 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

43 статьяның 2 пунктында:

- беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә бюджет чыгымнарының һәр максатчан статьясы буенча бюджет турындагы карар белән раслана.»;

- өченче абзацта «1 апрельдә» сүзләрен «1 февральдә» сүзләренә алмаштырырга;

46 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бюджет турында карар проектына бюджет ассигнованиеләрен муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре буенча бүлү турындагы карар белән расланган очракта, бюджет турында карар проектына муниципаль программаларның паспорты (паспорт проектлары) (күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары) тапшырыла.»;

51 статьяның 1 пунктында «составы һәм сроклары» сүзләрен «формалаштыру тәртибе, составы һәм сроклары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның 1.1 пунктының дүртенче абзацы 2027 елның 1 гыйнварыннан кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай районы Сәпәй авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Галиева Ф.Г.